РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ГЛАВА**
**Клянчеевского**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ул. Г.Тукая 7 с. Клянчеево, 422836
тел. (8377)33-4-31, факс: (8377) 33-4-31
ОКПО 93065179 ОГРН 1061672017990
ИНН/КПП 1622004620/1162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Келәнче**
**авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

Г.Тукай урамы, 7,Келәнче авылы, 422836,
тел. (8377)33-4-31, факс: (8377) 33-4-31
ОКПО 93065179 ОГРН 1061672017990
ИНН/КПП 1622004620/1162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**06.12.2021** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлегенең Келәнче авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1.2021 елның 16 декабрендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлегенең Келәнче авылының Г.Тукай һәм Кавказ урамнары, Бәки авылы Фрунзе урамы торак пунктларында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2021 елның 16 декабрендә 14 сәгатьтә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлегенең Келәнче авылының Татарстан һәм Комсомол урамнары торак пунктларында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлегенең Келәнче һәм Бәки авыллары торак пунктларында турыдан-туры яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән, җирлек территориясендә тавыш бирү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2022 елда 700 (җиде йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме”:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау ( сатып алу, ташу, вак таш җәю, су торбаларын урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү ) Келәнче авылында Татарстан һәм Г. Тукай урамы буенча урнашкан.;

- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) Келәнче һәм Бәки авылларында;

- Келәнче һәм Бәки авылларында юлларны грейдлау, кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Келәнче һәм Бәки авылларында авылны төзекләндерү (иске хуҗасыз төзелешләрне сүтү, шәхси киртәләрне сүтү, шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- чишмә территориясен төзекләндерү ( төзелеш материаллары сатып алу, павильон урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).;

- Келәнче авылында зират коймасын ремонтлау ( төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;

- каты көнкүреш калдыкларының вакытлыча полигоннарын тоту һәм чистарту( килешү буенча эшләр өчен түләү);

- янгын машинасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

«ӘЙЕ» «ЮК»

4. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Келәнче авылы, Г.Тукай ур., 35,
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Бәки авылы, Фрунзе ур., шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә 3(өч) көн эчендә урнаштырырга кирәк.

5. Әлеге карар халыкка игълан ителгән (басылып чыккан) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Келәнче авылы
җирлеге башлыгы Д.А.Кадыров.